КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 1 ноябрь г.Казань № 1397

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясен раслау турында» 2014 ел, 16 сентябрь, 666 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта «предприятиеләргә, учреждениеләргә» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре министрлыгына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы балаларына һәм яшьләренә патриотик тәрбия бирү концепциясендә:

II бүлектә «Россия Федерациясе Президенты«2020 елга кадәр Россия Федерациясе милли иминлек стратегиясе турында» 2009 елның 12 маендагы 537 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының хокукый актлары» сүзләрен «Россия Федерациясенең хокукый актлары һәм Татарстан Республикасының хокукый актлары» сүзләренә алмаштырырга;

IV бүлекнең утыз алтынчы абзацында «учреждениеләр һәм» сүзләрен төшереп калдырырга;

V бүлекнең ундүртенче абзацында «гомуми белем бирү оешмаларының, урта белем бирелә торган һөнәри мәгариф оешмаларының, югары белем бирелә торган мәгариф оешмаларының» сүзләрен төшереп калдырырга;

VIII бүлекнең дүртенче абзацында «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының патриотик тәрбия буенча координация советын төзү турында» 2018 ел, 12 февраль, 77 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 апрель, 309 нчы; 2019 ел, 3 июнь, 463 нче; 2020 ел, 21 февраль, 126 нчы; 2020 ел, 19 декабрь, 1157 нче; 2022 ел, 28 март, 278 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының патриотик тәрбия буенча координация советы турындагы нигезләмәгә, 5.5 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең кызыксынучы башкарма органнарына» сүзләрен «кызыксынучы республика башкарма хакимият органнарына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин